МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы

ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.04.2020 Казан шәһәре, № 18-49

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасының Дәүләт бурыч кенәгәсен алып бару тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2008 елның 30 маендагы 18–55 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Боерам:

1. «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасының Дәүләт бурыч кенәгәсен алып бару тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2008 елның 30 маендагы 18–55 номерлы боерыгына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге Боерык рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс
министрлыгының
2020 елның 21
апрелендәге 18-49
номерлы
боерыгы белән расланды

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасының Дәүләт бурыч кенәгәсен алып бару тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2008 елның 30 маендагы 18– 5 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

1. Боерык преамбуласында «3.1 пунктының 3.1.29 пунктчасы» сүзләрен «3.3 пунктның» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Бюджет сәясәте һәм финанс базарлары бүлеге» сүзләрен «Бюджет сәясәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт бурыч кенәгәсен алып баруның күрсәтелгән боерык белән расланган тәртибендә:

1 пунктта «бюджет сәясәте һәм финанс базарлары бүлеге (алга таба – ОБПиФР)» сүзләрен «бюджет сәясәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «ОБПиФР» аббревиатурасын «бюджет сәясәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бурыч кенәгәсендә электрон рәвештә эчке һәм тышкы дәүләт бурычы бирелешендә Татарстан Республикасының дәүләт бурыч йөкләмәләре төрләре буенча әлеге Тәртипкә 1 - 5 номерлы кушымталар нигезендә таблицалар форматында системалаштырылган мәгълүмат тупланган.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Бурыч кенәгәсендә бурыч йөкләмәләренең түбәндәге төрләре теркәлә:

– Татарстан Республикасының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре;

– Татарстан Республикасы тарафыннан кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар;

– Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

– Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре.»;

5 пунктта:

беренче абзацта «эчке бурыч» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктчаның беренче абзацында «, номиналь хакы Россия Федерациясе валютасында күрсәтелгән (1 нче кушымта)» сүзләрен «әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасы тарафыннан кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча:»;

3 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча, әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә форма буенча:»;

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендәге формага таянып, Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча:

теркәлү номеры;

дәүләт гарантиясен бирү өчен нигез;

дәүләт гарантиясенең датасы;

принципал исеме;

бенефициар исеме;

дәүләт гарантиясенең иң чик суммасы;

дәүләт гарантиясе белән тәэмин ителгән принципалның факттагы йөкләмәләре суммасы;

дәүләт гарантиясенең үз көченә керү датасы яки вакыты;

дәүләт гарантиясе сроклары, дәүләт гарантиясе буенча таләпләр кую, дәүләт гарантиясен үтәү сроклары;

дәүләт гарантиясе буенча йөкләмәләрнең тулы яки өлешчә үтәлеше, туктатылуы турында, шулай ук принципалның дәүләт гарантиясе белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен фактта барлыкка килү (арттыру) яисә туктату (киметү) турында белешмәләр;

гарантның принципалга карата регресс таләбе яисә гарантка бенефициарның принципалга карата таләбе хокукы бирү хокукы булу яисә булмау;

дәүләт гарантиясе шартларын ача торган башка белешмәләр.»;

6 һәм 7 пунктчаларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Бурыч кенәгәсендә Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен исәпкә алу йөкләмәләр барлыкка килү валютасында гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт бурычы составында чит ил валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре булган очракта, хисап (агымдагы) датасына Бурыч кенәгәсен формалаштырганда, чит ил валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасына хисап (агымдагы) датасына Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән көнгә күрсәтелгән валютаның рәсми курслары буенча исәпләнә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Бурычның нульле калдыгын күрсәтеп, туктатылган бурыч йөкләмәсе турында мәгълүмат бурыч йөкләмәләренең тиешле төренә караган бурыч йөкләмәләре составында, ул туктатылган елның 31 декабренә кадәр (шул көнне кертеп) саклана.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Бурыч йөкләмәсен кичектереп тору, йөкләмәләрне үтәү срокларын үзгәртү, процентларны һәм (яки) башка түләүләрне түләү күләмнәрен һәм (яисә) срокларын үзгәртү белән бәйле йөкләмәләрне үтәү шартларын үзгәртү өчен нигез булып торган бурычларны реструктуризацияләү Бурыч кенәгәсендә чагылдырылырга тиеш.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Бурыч кенәгәсендә операцияләрне исәпкә алу реаль вакыт режимында электрон рәвештә алып барыла. Бурыч кенәгәсе ай саен хисап датасына (айның 1 числосындагы 00 сәгатькә) кәгазь вариантта чыгарыла.»;

11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрне арттыру (киметү, түләү) турында мәгълүмат Бурыч кенәгәсенә хисаптан соң килүче айның беренче числосына ай саен кертелә.»;

14 пунктның икенче абзацында «6 һәм 7» сүзләрен «әлеге Тәртипнең 5 нче кушымтасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Бурыч йөкләмәләрен теркәү бурыч йөкләмәсенең теркәү номерын хронологик тәртиптә бирү һәм тиешле язмаларны бюджет сәясәте бүлеге тарафыннан Бурыч кенәгәсенең тиешле бүлегенә кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен теркәү сигез әһәмиятле разрядтан торган теркәү номерын бирү юлы белән гамәлгә ашырыла:

X1X2X3X4X5X6X7X8.

а) номерның беренче, икенче разрядлары (X1X2) Дәүләт бурыч йөкләмәләренең типын күрсәтә:

«01» – йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләре өчен;

«02» – йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән кредит оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар өчен;

«03» – йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән халыкара финанс оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар өчен;

«04» – йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән чит ил банкларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар өчен;

«05» – йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына җәлеп ителгән бюджет кредитлары өчен;

«06» – Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре өчен;

«07» – йөкләмәләре чит ил валютасында белдерелгән Татарстан Республикасы Дәүләт кыйммәтле кәгазьләре өчен;

«08» – йөкләмәләре чит ил валютасында белдерелгән халыкара финанс

оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар өчен;

«09» – йөкләмәләре чит ил валютасында белдерелгән чит ил банкларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар өчен;

«10» – максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән Татарстан Республикасы бюджетына чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары өчен;

«11» – чит ил максатчан кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан чит ил валютасында Татарстан Республикасының дәүләт гарантияләре өчен.

б) өченче, дүртенче, бишенче разрядлар (Х3Х4Х5) Россия дәүләт стандарты һәм Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән санлы валюта кодларын күрсәтәләр.

в) алтынчы, җиденче разрядлар (Х6Х7) бурыч йөкләмәсенең тәртип номерын күрсәтәләр.

г) сигезенче разряд (Х8) – «S» хәрефе– Татарстан Республикасының дәүләт бурыч йөкләмәсе Россия Федерациясе валютасында белдерелгән, «V» хәрефе Татарстан Республикасының дәүләт бурыч йөкләмәсе чит ил валютасында белдерелгән дип күрсәтә.»;

17 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

18 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«18) Бурыч кенәгәсе электрон рәвештә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы бюджет сәясәте бүлегенең персональ компьютерларында һәм мәгълүматлар базасында электрон файллар рәвешендә саклана, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының эш номенклатурасы белән билгеләнгән саклау сроклары нигезендә бюджет сәясәте бүлегендә кәгазь вариантта саклана.»;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«19) Бурыч кенәгәсендә бурыч йөкләмәсен теркәү өчен нигез булып торган мәгълүмат исәп, хисап бүлегендә һәм бюджет сәясәте бүлегендә саклана.»;

1– 5 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

6 нчы һәм 7 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт бурыч кенәгәсен алып бару тәртибенә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2020 елның 21 апрелендәге 18-49 номерлы боерыгы редакциясендә) 1 нче кушымта

20__ елның «01» ______________ Формасы

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы

Татарстан Республикасының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре турында мәгълүмат

| | Кыйммәтле кәгазьләр чыгаруның дәүләт теркәү номеры | Кыйммәтле кәгазь төре | Кыйммәтле кәгазь чыгару формасы | Эмиссия шартларының теркәү номеры | Эмиссия шартларының дәүләт теркәү датасы (Эмиссия шартларына үзгәрешләр) | Кыйммәтле кәгазьләр чыгару (өстәмә чыгару) турында карар кабул ителгән хокукый актның исеме, актны кабул иткән орган исеме, актның датасы, номеры | Йөкләмәләрнең валютасы | Бер кыйммәтле кәгазьнең номиналь бәясе (сум) | Эмиссия шартлары белән каралган кыйммәтле кәгазьләр ияләренә чикләүләр | Генераль агент исеме | Депозитарий яки регистратор исеме | Сәүдәне оештыручы исеме | Номиналь бәя буенча кыйммәтле кәгазьләр чыгаруның (өстәмә чыгару) игълан ителгән күләме (сум.) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Татарстан Республикасының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре | | | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | |
| Йөкләмәләре чит ил валютасында белдерелгән Татарстан Республикасының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре | | | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | |
| Барлыгы | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | |

| Кыйммәтле | Кыйммәтле кәгазьләр | Һәр купон чоры буенча | Купон | Түләнергә тиешле | Купон | Купон | Урнаштыру | Кыйммәтле | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| кәгазьләр урнаштыру (урнаштырып бетерү) датасы | урнаштыру күләме (номиналь бәя буенча) (сум.) | купон кереме түләүнең билгеләнгән датасы | кеременең процент ставкасы | купон кереме суммасы (сум.) | кереме түләүнең фактагы датасы | кеременең түләнгән суммасы (сум).) | вакытында билгеләнгән дисконт суммасы (сум.) | кәгазьләрне түләгәндә (сатып алганда) дисконт суммасы (сум.) | Кыйммәтле кәгазьләр сатып алу датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 |
| | | | | | | | | | |
| X. | | X. | X. | | X. | | | | X. |
| | | | | | | | | | |
| X. | | X. | X. | | X. | | | | X. |
| X. | | X. | X. | | X. | | | | X. |

| Номиналь бәя буенча кыйммәтле кәгазьләрне сатып алу күләме (сум.) | Кыйммәтле кәгазьләр каплауның билгелән гән датасы | Билгеләнгән даталарга түләнергә тиешле кыйммәтле кәгазьләрнең номиналь бәясе суммасы (сум.) | Кыйммәтле кәгазьләрне каплауның фактагы датасы | Кыйммәтле кәгазьләр не каплауның фактагы күләме (сум.) | Һәр купон чоры өчен купон керемен түләү буенча срогы чыккан бурыч суммасы (сум) | Кыйммәтле кәгазьләрнең номиналь бәясен каплау буенча түләү срогы чыккан бурыч суммасы (сум) | Кыйммәтле кәгазьләр буенча йөкләмәләрне үтәү буенча түләү срогы чыккан бурыч суммасы (сум) | Йөкләмәләр валютасында дәүләт кыйммәтле кәгазьләре буенча бурычның номиналь суммасы | Дәүләт кыйммәтле кәгазьләре буенча бурычның номиналь суммасы (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 | 31 | 32 | 33 | 34 |
| | | | | | | | | | |
| | X. | | X. | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| | X. | | X. | | | | | | |
| | X. | | X. | | | | | X. | |

Бюджет сәясәте бүлеге башлыгы

_______________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт бурыч кенәгәсен алып бару тәртибенә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2020 елның 21 апрелендәге 18-49 номерлы боерыгы редакциясендә) 2 нче кушымта

Формасы

20__ елның «01» _____________

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы

Татарстан Республикасы тарафыннан кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар турында мәгълүмат

| | Бурыч йөкләмәләре барлыкка килгән документның исеме | Документның датасы, номеры, транш номеры | Яңа шартнамә(ләр)/килешү(ләр) төзүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан шартнамә(ләр)/килешү(ләр)нең датасы, номеры | Шартнамә/килешүнең датасы, номеры | Кредит орнын исеме | Йөкләмәләрнең валютасы | Кредит алу датасы | Процент ставкасы (еллык %) | Процент түләүләренең билгеләнгән түләү даталары | Түләнергә тиешле процент түләүләре суммасы (сум.) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән кредит оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар | | | | | | | | | | |
| Йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән халыкара финанс оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар | | | | | | | | | | |
| Йөкләмәләре Россия | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Федерациясе валютасында белдерелгән чит ил банкларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | |
| Йөкләмәләре чит ил валютасында белдерелгән халыкара финанс оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар | | | | | | | | | | |
| Йөкләмәләре чит ил валютасында белдерелгән чит ил банкларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | |
| Барлыгы | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | |

| Процент түләүләренең фактагы түләү датасы | Процент түләүләренең фактагы түләү суммасы (сум.) | Кредитны түләүнең шартнамәдә/килешүдә билгеләнгән датасы | Кредит түләүнең шартнамәдә/килешүдә билгеләнгән даталарда түләнергә тиеш суммасы (сум.) | Кредит каплауның фактагы датасы | Кредитны каплауның фактагы күләме (сум) | Процентлар түләү буенча түләү срогы чыккан бурыч суммасы (сум) | Кредит буенча төп бурычны түләү буенча түләү срогы чыккан бурыч суммасы (сум) | Кредит буенча түләү срогы чыккан бурыч суммасы (сум) | Йөкләмә валютасында кредит буенча төп бурыч | Кредит буенча төп бурыч күләме (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| Х. | | Х. | | Х. | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| Х. | | Х. | | Х. | | | | | | |
| Х. | | Х. | | Х. | | | | | Х. | |

Бюджет сәясәте бүлеге башлыгы ________________________________

(имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт бурыч кенәгәсен алып бару тәртибенә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2020 елның 21 апрелендәге 18-49 номерлы боерыгы редакциясендә) 3 нче кушымта

Формасы

20__ елның «01» ______________

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы

Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җәлеп ителгән бюджет кредитлары турында мәгълүмат

| | Бурыч йөкләмәләре барлыкка килгән документның исеме | Документның датасы, номеры, транш номеры | Яңа шартнамә(ләр)/килешү(ләр) төзүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан шартнамә(ләр)/килешү(ләр)нең датасы, номеры | Шартнамәгә/килешүгә үзгәрешләр датасы, номеры | Бюджет кредиты бирелгән бюджет | Йөкләмәләрнең валютасы | Бюджет кредитын алу датасы | Процент ставкасы (еллык %) | Процент түләүләренең билгеләнгән түләү даталары | Түләнергә тиешле процент түләүләре суммасы (сум.) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына җәлеп ителгән бюджет кредитлары | | | | | | Х. | | | | |
| Барлыгы | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | |
| Максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән Татарстан Республикасы бюджетына чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барлыгы | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | |

| Процент түләүләре нең фактагы түләү датасы | Процент түләүләре нең фактагы түләү суммасы (сум.) | Шартнамәдә/ килешүдә билгеләнгән бюджет кредитын каплау датасы | Шартнамәдә/килешүдә билгеләнгән даталарда түләнергә тиешле бюджет кредитын каплау суммасы (сум) | Бюджет кредитын каплау ның фактагы датасы | Бюджет кредитын каплауның фактагы күләме (сум) | Процентлар түләү буенча түләү срогы чыккан бурыч суммасы (сум) | Бюджет кредиты буенча төп бурычны түләү буенча түләү срогы чыккан бурыч суммасы (сум) | Бюджет кредиты буенча түләү срогы чыккан бурыч суммасы (сум) | Йөкләмә валютасында бюджет кредиты буенча төп бурыч күләме | Бюджет кредиты буенча төп бурыч күләме (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
| | | | | | | | | | | |
| X. | | X. | | X. | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| X. | | X. | | X. | | | | | | |
| X. | | X. | | X. | | | | | X. | |

Бюджет сәясәте бүлеге башлыгы

________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт бурыч кенәгәсен алып бару тәртибенә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2020 елның 21 апрелендәге 18-49 номерлы боерыгы редакциясендә) 4 нче кушымта

Формасы

20__ елның «01» _____________

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы

Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре турында мәгълүмат

| | Гарантия датасы номеры | Гарантия белән тәэмин ителгән бурыч йөкләмәсе буенча бурычларны реструктуризацияләүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан гарантиянең датасы, номеры | Гарантиягә үзгәрешләр нең датасы, номеры | Йөкләмәнең валютасы | Оешма – гарант атамасы: | Оешма – принципал атамасы: | Оешма – бенефициар атамасы: | Гарантиянең үз көченә керү датасы | Гарантиянең гамәлдә булу вакыты | Гарантия буенча таләпләр кую вакыты | Гарантка билгеләнгән тәртиптә таләпләр куелганнан соң гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү срогы | Гарант тарафыннан гарантия буенча йөкләмәләрне үтәүнең факттагы датасы | Гарант тарафыннан гарантия буенча йөкләмәләрнең үтәлешенең факттагы күләме (сум) | Гарантның гарантияне үтәү буенча бурычы (сум) | Йөкләмәләр валютасында гарантия буенча йөкләмәләр күләме | Гарантия буенча йөкләмәләр күләме (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | Х. | | | | |
| Максатчан чит ил кредитларын | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| куллану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан чит ил валютасында бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | | | | |
| Барлыгы | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | X. | | | X. | |

Бюджет сәясәте бүлеге башлыгы ______________________________

(имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында
Татарстан Республикасы Дәүләт бурыч кенәгәсен
алып бару тәртибенә (Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының 2020 елның 21 апрелендәге
18-49 номерлы боерыгы редакциясендә)
5 нче кушымта

Формасы

**Татарстан Республикасының Дәүләт бурыч кенәгәсе**

202_ елның __

| | Йөкләмә төре | Бурыч йөкләмәләре күләме, чит ил валютасы | Бурыч йөкләмәләре күләме, сумнар |
|---|---|---|---|
| Эчке дәүләт бурычы, шул исәптән: | | X | |
| 1 | Йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Татарстан Республикасы Дәүләт кыйммәтле кәгазьләре (1 нче кушымта) | X | |
| 2 | Йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән кредит оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар (2 нче кушымта) | X | |
| 3 | Йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән халыкара финанс оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар (2 нче кушымта) | X | |
| 4 | Йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән чит ил банкларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар (2 нче кушымта) | X | |
| 5 | Йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына җәлеп ителгән бюджет кредитлары (3 нче кушымта) | X | |
| 6 | Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре (кушымта № 4) | X | |
| Тышкы дәүләт бурычы, шул исәптән: | | | X |
| 1 | Йөкләмәләре чит ил валютасында белдерелгән Татарстан Республикасының дәүләт кыйммәтле | | X |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кәгазьләре (1 нче кушымта) | | |
| 2 | Йөкләмәләре чит ил валютасында билгеләнгән халыкара финанс оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар (2 нче кушымта) | | X |
| 3 | Йөкләмәләре чит ил валютасында билгеләнгән чит ил банкларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар (2 нче кушымта) | | X |
| 4 | Максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән Татарстан Республикасы бюджетына чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары (3 нче кушымта) | | X |
| 5 | Максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан чит ил валютасында бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре (4 нче кушымта) | | X |
| Татарстан Республикасының тышкы дәүләт бурычын Россия Федерациясе Үзәк Банкы курсы буенча сумнарда бәяләү | | X | |
| Татарстан Республикасы дәүләт бурычының сумнарда гомуми күләме | | X | |